# КАРАР

## Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Прости авыл җирлеге составына керүче Прости торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

2023 елның 20 октябре № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2023 елның 20 октябрендә уздырылган «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Прости авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2024 елда үзара салым кертүгә 500 сум күләмендә ризалыгыгыз бармы, моңа 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, махсус хәрби операция зонасында хезмәт итүче гражданнарның гаилә әгъзалары, укытуның көндезге формасында белем алучы студентлар; 2 төркем инвалидлар 50 процент күләмендә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җибәрергә:

- Кайманов урамы, 60 нчы йорт чатыннан Подгорная урамы юнәлешендә юл полотносын ремонтлау.

Гражданнарның 2 сум 83 тиен күләмендә җыелган үзара салым акчаларының калган өлеше, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының 24.10.2021г. №2 торак пунктында гражданнар җыены карары нигезендә, Полевая урамы юнәлешендә 2 нче йорт (килешү буенча эшләр өчен түләү), Кайманов урамы, 60 нчы йорт адресы буенча Подгорная урамы юнәлешендә юл полотносын ремонтлауга юнәлдерергә

«ӘЙЕ» «ЮК»

мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 505 җыенда катнашучы граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан җыенда катнашучы гражданнар саны 263 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучы гражданнар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 244 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 19 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Прости авыл җирлеге составына керүче Прости торак пунктында гражданнар җыенын булган дип, халык җыены нәтиҗәләрен чын дип таныргa.

2. «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Прости авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2024 елда үзара салым кертүгә 500 сум күләмендә ризалыгыгыз бармы, моңа 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, махсус хәрби операция зонасында хезмәт итүче гражданнарның гаилә әгъзалары, укытуның көндезге формасында белем алучы студентлар; 2 төркем инвалидлар 50 процент күләмендә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җибәрергә: - Кайманов урамы, 60 нчы йорт чатыннан Подгорная урамы юнәлешендә юл полотносын ремонтлау.

3. Гражданнарның 2 сум 83 тиен күләмендә җыелган үзара салым акчаларының калган өлеше, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының 24.10.2021г. №2 торак пунктында гражданнар җыены карары нигезендә, Полевая урамы юнәлешендә 2 нче йорт (килешү буенча эшләр өчен түләү), Кайманов урамы, 60 нчы йорт адресы буенча Подгорная урамы юнәлешендә юл полотносын ремонтлауга юнәлдерергә

«ӘЙЕ» «ЮК»

мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларына, Прости авыл җирлеге сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Прости авыл җирлеге башлыгы

Совет Простинского сельского поселения

Д.А. Бәдәртинов